**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Пүскән авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**14 декабрь 2021 ел** **№2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына карата, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Пүскән авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 100 % күләмендә ташлама каралган I нче төркем инвалидларын, тыл хезмәтчәннәрен, 80 яшьтән узган өлкәннәрне, ялгыз яшәүче, балалары булмаган 70 яшьтән узган өлкәннәрне исәпкә алмаганда, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең Пүскән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданнарга 2022 нче елда үзарасалымны 3000 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәйкәленен территориясен төзекләндерү;
- «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пүскән авылында иҗтимагый-мәдәни үзәк төзелеше» дип аталган корылмага проект-смета документлары эшләү һәм дәүләт экспертизасы үткәрү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлеге Советының мәгълүмәти стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет Рәисе

Шарипҗанов Р.Н.